**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** 23.09.2019

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** №1617

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында” 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Админстратив хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында”, 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында”, 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. 2.1 статьясы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешманың элмә такталарында үз исемен һәм башка элмә такталарда күрсәтелергә тиешле мәгълүматны күрсәткәндә Татарстан Республикасының телләре турында законнарны бозуга карата), 2.4 - 2.8, 2.12 - 2.14 статьялары, 2.15 статьясының 2 бүлеге, 3.2 - 3.8, 3.10 статьялары (гражданнарга карата), 3.11, 3.14 - 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьялары (билгеле муниципаль берәмлекләр территориясендә тормышка ашырыла торган муниципаль йөртүләргә карата), Админстратив хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы (кушымта нигезендә) белән күздә тотылган тәртиптә, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген ачыкларга.

1.2. Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегеннән Советның оештыру бүлеге начальнигын, Советның баш белгеч-юристын, Биектау муниципаль районы Советының ришвәтчелеккә каршы тору мәсьәләләре буенча башлык ярдәмчесен, террорчылыкка каршы көрәш комиссиясе сәркатибен, мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисен алырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында”, 2019 елның 26 июлендәге 1158 номерлы карарын, “Биектау муниципаль районы башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында”, 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында”, 2019 елның 12 августындагы 1159 номерлы карарын бетерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Афанасьев А.П. ка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин